**Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты эш кәгазьләрен алып бару идарәсе архив бүлегенең 2018 елдагы эшчәнлеге турында хисап**

2018 елга билгеләнгән план-йөкләмәләр түбәндәге күрсәткечләр буенча үтәлде:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 20 ноябрендәге **2992-р** санлы боерыгы нигезендә Яр Чаллы шәһәре архив бүлегенең архив саклау урыннарына капиталь ремонт үткәрүгә 1406,495 мең сум күләмендә финанслау лимиты расланды. Архив саклау урынының **4 залы** тулысынча ремонтланды. Шуның өчесендә яңа стеллажлар урнаштырылды. **44016 саклау берәмлеге** документ архив бүлеге белгечләре тарафыннан стеллажларга куелды.









Татарстан Республикасы бюджетыннан архив эше өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыруга бирелгән субвенция VIP NET программасы белән эшләүгә (6810,00 сум), 2 нче санлы архив саклау урынында вентиляция системасы урнаштыруга (157242,00 сум), шулай ук гигрометрлар сатып алуга, архив саклау урыннары өчен табличкалар ясатуга тотылды. Сатулар электрон мәйданчык аркылы башкарылды.



Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 21 апрелендәге 757-р санлы боерыгының 6.3 пункты һәм Россия Федерциясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча Координация советының киңәйтелгән утырышы йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты йөкләмәләренең беркетмәләрен үтәү йөзеннән, Яр Чаллы шәһәренең озак дәвалануга мохтаҗ балалар өчен санаторий тибындагы «90 нчы санатор мәктәп-интернаты» ДБББСУ, «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм ителгән балалар өчен 71 нче (VIII төрдәге) махсус (коррекция) мәктәп-интернаты» ДББУның шәхси состав буенча документлары архив бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан тәртипкә китерелде, тегеп куелды һәм

описька алынды. Әлеге документлар архив бүлегенә эшкәртелмәгән килеш (хуҗасыз архив) кергән иде. Яр Чаллы шәһәренең озак дәвалануга мохтаҗ балалар өчен санаторий тибындагы «90 нчы санатор мәктәп-интернаты» ДБББСУ, «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм ителгән балалар өчен 71 нче (VIII төрдәге) махсус (коррекция) мәктәп-интернаты» ДББУның исемнәрен алмаштыру турындагы мәгълүматлар «Яр Чаллы шәһәре хакимияте»нең архив фонды документлары һәм «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Яр Чаллы шәһәрендәге мәгариф идарәсе фонды», шулай ук шәхси состав буенча директор приказлары һәм делоларның исемнәре буенча торгызылды.

**2 фондта** документларны тегү эшләре башкарылды**, барлыгы 686 саклау берәмлеге.**

**9 фондта документлар картонлап куелды, барлыгы 2268 саклау берәмлеге.**



Татарстан Республикасы Дәүләт комитетының «2018 елга муниципаль архивларның эшен планлаштыру һәм аларның 2017 ел өчен хисаплылыгы турында» 2017 елның 19 октябрендәге 01-02/1519 санлы Хаты нигезендә дәүләт (Татарстан Республикасы) милкенә кертелгән делоларның барлыгын һәм аларның торышын тикшерү үткәрелде. Татарстан Республикасының Архив эшләре буенча Дәүләт комитетына **19631 саклау берәмлеге** акт документлары тапшырылды.

2018 елда кабул ителгән түбәндәге фондлар шулай ук **тикшерү үтте**:

- Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәр суды;
- «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасы» МКУ;

- Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты;

- «Яр Чаллы сәнгать көллияте» ДАҺББУ;

- «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм ителгән балалар өчен 71 нче (VIII төрдәге) махсус (коррекция) мәктәп-интернаты» ДББУ;


- Татарстан Республикасы «Яр Чаллы татар дәүләт драма театры» ДАМУ **Барлыгы 21729 саклау берәмлеге.**

Дәүләт (Татарстан Республикасы) милкенә кертелгән 43 фондта һәм 2018 елда кабул итеп алынган түбәндәге фондларда исәпкә алу **документлары тикшереп чыгылды:**

ТАССР Шереметьевск районы Красноярск авыл Советы башкарма комитеты; Яр Чаллы шәһәренең озак дәвалануга мохтаҗ балалар өчен санаторий тибындагы «90 нчы санатор мәктәп-интернаты» ДБББСУ; Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының икътисад һәм социаль планлаштыру идарәсе»; Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәр суды; «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасы» МКУ; Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты; «Яр Чаллы сәнгать көллияте» ДАҺББУ; Татарстан Республикасы «Яр Чаллы татар дәүләт драма театры» ДАМУ; «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм ителгән балалар өчен 71 нче (VIII төрдәге) махсус (коррекция) мәктәп-интернаты» ДББУ. **Барлыгы 52 фонд.**

2018 елда «Архив фонды»ның мәгълүмат базасына саклау берәмлекләренең описьларын кертү эше дәвам итте. 2018 елның 10 декабрендәге торышы буенча **Татарстан Республикасы Бердәм архив мәгълүматы системасына (ЕАИС)** кертелгән документларның гомуми саны **45168 саклау берәмлеге**.

2018 елда Татарстан Республикасы Архив эшләре буенча Дәүләт комитетының архивка капиталь ремонт үткәрү, Бердәм архив мәгълүматы системасында эшләү, архив документларын комплектлаштыру, исәпкә алу, файдалану буенча эшләүдә **97 йөкләмә** үтәлде. Яр Чаллы шәһәр судыннан – 10, Яр Чаллы шәһәре прокуратурасыннан – 4, Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының Мәгълүмат үзәгеннән – 2, Татарстан Республикасының Яр Чаллы буенча Тикшерү идарәсеннән 1 запрос керде.




2018 елда **8 административ регламентка** 2 тапкыр үзгәрешләр кертелде.

**«Татарстан Республикасының Архив фондын формалаштыру. Ведомстводагы архивларны һәм учреждение, оешма, предприятие документларын эш производствосында оештыруга оештыру-методик җитәкчелек»**


**Идарә итү документларын кабул итү** түбәндәге фондларда алып барылды: ТАССР Шереметьевск районы Красноярск авыл Советы башкарма комитеты (1931 – 1947 еллар өчен – 8 саклау берәмлеге); Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының икътисад һәм социаль планлаштыру идарәсе» (2006 – 2011 еллар өчен – 17 саклау берәмлеге); Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәр суды; «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасы» МКУ; Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты; «Яр Чаллы сәнгать көллияте» ДАҺББУ; Татарстан Республикасы «Яр Чаллы татар дәүләт драма театры» ДАМУ. **Барлыгы 1582 саклау берәмлеге.**

**Шәхси состав буенча документлар кабул итү** түбәндәге фондларда алып барылды:

«Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм ителгән балалар өчен 71 нче (VIII төрдәге) махсус (коррекция) мәктәп-интернаты» ДББУ. **Барлыгы 541 саклау берәмлеге.**

Татарстан Республикасы Архив эшләре буенча Дәүләт комитетының Эксперт-тикшерү һәм методик комиссиясенә **идарә итү буенча документ описьларын** раслау **7 фондта** башкарылды, **барлыгы 1809 саклау берәмлеге.**

**Аеруча зур әһәмияткә ия документ описьларын раслау** «ТАССР хезмәт ияләре халык депутатларының Яр Чаллы шәһәр Советы» (1942-1943 еллар өчен – **2 саклау берәмлеге)**.



Список

работающих эвакуированных в Н.-Челнинской средней школе имени Димитрова на 8 января 1942 года

| Фамилия, имя и отчество | Откуда эвакуирован | Национальность | Занимаемая должность в данном учреждении | Основная профессия |
|---|---|---|---|---|
| Маккавеева Анна Ивановна | из г. Минска | Русская | учительница | учительница |
| Рожинсон Зинаида Анатол. | — " — | Еврейка | — " — | — " — |
| Тривен Роза Ароновна | из м. Жмеринка | Еврейка | — " — | — " — |
| Фролова Наталия Фрол. | из г. Острова Ленинградской области | Русская | уборщица | [illegible] |
| Федорова Антонина | — " — | Русская | — " — | — " — |
| Шестаков Михаил Алекс. | из г. Москвы | Русский | учитель | учитель. |
| Шейгам Берта Самуиловна | — " — | Еврейка | — " — | учительница |

Директор школы [illegible]

8/I-1942 года

Татарстан Республикасы Архив эшләре буенча Дәүләт комитетының Эксперт-тикшерү һәм методик комиссиясенә **шәхси состав буенча документ описьларын раслау 2 фондта башкарылды, барлыгы 686 саклау берәмлеге.**

Татарстан Республикасы Архив эшләре буенча Дәүләт комитетының Эксперт-тикшерү һәм методик комиссиясенә түбәндәгеләр **эшләнде һәм килештерелде**:

- **делолар номенклатурасы**:

- Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре прокуратурасы;

**- архив һәм эксперт комиссиясе турында нигезнамә:**

- Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре прокуратурасы;

- Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәр суды;

- Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының финанс идарәсе;

- Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе;

**- эш кәгазьләре белән эшләү буенча инструкция**

- Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре буенча Россия Федераль салым хезмәте инспекциясе.

Архив эшләре өлкәсендә дәүләт (3 хезмәт) һәм муниципаль (4 хезмәт) хезмәтләр күрсәтүгә зур игътибар бирелде. Юридик затларга архив эшендә һәм документлар белән эшләүне оештыру, делолар номенклатурасын, даими саклanыштагы һәм шәхси состав буенча документ описьларын төзүгә методик һәм практик ярдәм күрсәтү буенча түбәндәге **19 оешмага муниципаль хезмәт** күрсәтелде: Яр Чаллы шәһәр суды (җинаять эшләре), Яр Чаллы шәһәр суды (гражданлык эшләре), Яр Чаллы татар дәүләт драма театры, «Домкор» ААҖ, Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Яр Чаллы шәһәре территориаль бүлеге, ТР «Яр Чаллы сәнгать көллияте» ДАҺББУ, «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасы» МКУ, Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты, Яр Чаллы шәһәренең «Болгар» бию театры» МАМУ, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре буенча Россия Федераль салым хезмәте инспекциясе, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының финанс идарәсе, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе, Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының икътисад һәм социаль планлаштыру идарәсе, «Мәгълүмати-методик үзәк» МБУ, шәһәр Башкарма комитетының Автозавод районы Хакимияте, шәһәр Башкарма комитетының Комсомол районы Хакимияте, шәһәр Башкарма комитетының Үзәк районы Хакимияте, «Яр Чаллы шәһәренең халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДБУ.

Яңа комплектлаштыру чыганакларын ачыклау буенча эш дәвам иттерелә, шул максатларда 2018 елда «Мәгълүмати-методик үзәк» МБУда, Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсендә, Яр Чаллы шәһәренең «Болгар» бию театры» МАМУда ачылган документлар исемлеге өйрәнелде. Нәтиҗәдә:

- Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының икътисад һәм социаль планлаштыру идарәсе комплектлаштыру чыганаклары буенча архив бүлегенең 1 нче санлы Исемлегеннән чыгарылды.

- «Мәгълүмати-методик үзәк» МБУ, Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе, Яр Чаллы шәһәренең «Болгар» бию театры» МАМУ комплектлаштыру чыганаклары буенча архив бүлегенең 1 нче санлы Исемлегенә кертелде.

**«Мәгълүмати-эзләү системасын булдыру, фәнни мәгълүматтан һәм документлардан файдалану»**




Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 25 февралендә республиканың шәһәр һәм районнарында 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышының 73 еллыгын бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыруга багышланган массакүләм чараларны оештыру буенча үткәргән киңәшмәсенең 8-пр санлы беркетмәсенең 4 пунктын үтәү йөзеннән, Җиңү бәйрәме алдыннан «КидСпейс» балалар шәһәрчегендә Яр Чаллы шәһәре өчен «Без солдат хатларын онытмыйбыз...» дип аталган үзенчәлекле чара үткәрелде. Аны оештыручылар – «КидСпейс» балалар шәһәрчеге һәм Башкарма комитетның архив бүлеге. Чарага Чаллының билгеле шәхесләре чакырылды, алар арасында: «Планета Фитнес» спорт-сәламәтләндерү клубының генераль директоры Эдуард Жестков, «Аталар берлеге» региональ иҗтимагый оешмасы рәисе Юрий Соленов, Яр Чаллы татар дәүләт драма театры директоры Рашат Фәйзерахманов, «Ачкыч» театрының сәнгать җитәкчесе Софья Федекина, «КАМАЗ» футбол клубының генераль директоры Айнур Миңнеханов һәм башкалар бар иде. Алар солдатларның әниләренә, сөйгән ярларына, балаларына, якыннарына фронттан язган хатларының

төп нөсхәләрен укыдылар. Хатлар Татарстан Республикасының Дәүләт милли архивыннан алынды. Һәр хат тарихы – еракта калган сугыш елларының тулы бер буыны ул.

Яр Чаллы дәүләт педагогия университетының «тарих» белгечлеге алучы студентлары өчен архив саклау урыннары буенча экскурсия үткәрелде. Аларга 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы чорының кызыклы документлары күрсәтелде. Экскурсиядә 30 кеше катнашты.


Россия Архив хезмәтенең 100 еллыгына багышлап **15 чара** оештырылды:

1. 2018 елның 30 июлендә – Татарстан Республикасы Архив эшләре буенча Дәүләт комитетының Эксперт-тикшерү һәм методик комиссиясенең күчмә утырышы үткәрелгән көнне шәһәр Башкарма комитетында архив фондларыннан алынган документлар буенча «Кама елгасын буу», «Камадагы гигант», «Нәни камазлылар ничек үсеп җитте» дип аталган фотокүргәзмәләр;


2. 2018 елның 30 июлендә Татарстан Республикасы Архив эшләре буенча Дәүләт комитетының Эксперт-тикшерү һәм методик комиссиясенең Яр Чаллыдагы күчмә утырышы шәһәрнең «Челнинские известия» газетасында яктыртылды;

3. 2018 елның 31 июлендә архив фондларыннан алынган документлар буенча «Кама елгасын буу», «Камадагы гигант», «Нәни камазлылар ничек үсеп җитте» дип аталган фотокүргәзмәләр шәһәр Башкарма комитеты хезмәткәрләренә дә күрсәтелде;

4. 2018 елның 8 августында шәһәрнең «Челнинские известия» газетасы битләрендә Яр Чаллы шәһәр суды документларының сакланышы турында «Уллыкка бала алу сере» дигән мәкалә басылды;




5. 2018 елның 5 сентябрендә шәһәрнең «Челнинские известия» газетасында «Кайбер Чаллы бизнесменнарының караңгы үткәне билгеле булды» мәкаләсе дөнья күрде.




6. 2018 елның 6 сентябрендә Яр Чаллы шәһәре сайтында «Мин яратам сине, туган шәһәрем, син иң шәбе һәм иң яше» фотокүргәзмәсе оештырылды;

7. 2018 елның 12 сентябрендә Яр Чаллы шәһәре сайтында «Архив документлары ниләр турында сөйли» виртуаль күргәзмәсе урнаштырылды;




8. 2018 елның 3 октябрендә Яр Чаллы шәһәренең «Энергетик» мәдәният сараенда жирле үзидарә органнары хезмәткәрләре өчен Өлкәннәр көненә багышланган «Бу синең белән минем язмыш – безнең биография» фотокүргәзмәсе оештырылды;




9. 2018 елның 5 октябрендә Яр Чаллы шәһәре сайтында Укытучылар көненә багышланган күргәзмә оештырылды;
10. 2018 елның 10 октябрендә шәһәрнең «Шәһри Чаллы» газетасы битләрендә архив бүлегенең эшен яктырткан «Телсез шаһитлар белән эшләүчеләр» мәкаләсе басылды;

11. 2018елның 15 октябрендә Яр Чаллы шәһәренең архив бүлеге сайтында «30, 40, 50 ел элек бу көнне шәһәр газеталары ниләр турында

язды» дигән мәгълүмати материал урнаштырылды;

12. 2018 елның 20 октябрендә Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының эш кәгазьләрен алып бару идарәсе архив бүлеге башлыгы «Челнинские известия» газетасы өчен шәһәр архивы эшчәнлеге турында интервью бирде;

13. 2018елның 25 октябрендә Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының эш кәгазьләрен алып бару идарәсе архив бүлеге башлыгы «Чаллы-ТВ» радиотелекомпаниясе өчен «Архив – кичә һәм бүген» дигән темага интервью бирде;




14. 2018 елның 28 октябрендә шәһәрнең «Энергетик» мәдәният сараенда Бөтенсоюз ленинчыл коммунистик яшьләр союзының 100 еллыгына багышлап «Бу синең белән минем язмыш – безнең биография» фотокүргәзмәсе оештырылды;

15. 2018 елның 9 ноябрендә шәһәрнең «Челнинские известия» газетасында «Бай түрәләргә дә конфискация белән 10 ел биргәннәр, ярлыларга да» дип исемләнгән мәкалә басылып чыкты.

Татарстан Республикасы Архив хезмәтенә 100 ел тулу уңаеннан шәһәрнең 5 – 7 сыйныф укучылары өчен **18 дәрес** уткәрелгән.

Архивта саклана торган документларны муниципаль архивның уку залында эш өчен файдаланучыга биреп тору буенча **8 дәүләт хезмәте күрсәтелгән.**

официальный сайт города
Набережные Челны

Поиск поиск

новости мэрия о городе инвесторам обращения граждан афиша челны 2030 войти

Все новости / Обзор новости

Учащиеся школы №17 побывали на экскурсии в архивной службе автограда

В рамках празднования 100-летия архивной службы Республики Татарстан в архивном отделе Исполнительного комитета города прошла экскурсия для учеников седьмого класса средней школы № 17. Начальник архивного отдела **Люция Шамсевалиева** рассказала школьникам о том, какие документы хранятся в архивах города. Ученикам особенно понравился рассказ о периоде «Город Набережные Челны в годы Великой Отечественной войны».





Түбәндәге тикшеренү темалары һәм курс эшләре өчен кирәкле булган **263 дело** бирелгән:

- Яр Чаллы шәһәренең мәдәният сарайлары тарихы;
- Яр Чаллы шәһәре һәйкәлләре;
- 1980-1990 елларда Яр Чаллы шәһәрендә профессиональ спортның үсеше;

- «КАМАЗ» җитештерү берләшмәсенең генераль директоры Л.В. Васильевның портреты;

- сугыштан соңгы елларда Яр Чаллыда нинди җинаятьләр буенча хөкем иткәннәр;

- Яр Чаллы – Бөек Ватан сугышы елларында;

- Яр Чаллы шәһәрендә пионерлар хәрәкәте.

Күпфункцияле үзәк белгечләре өчен «Күпфункцияле үзәктә архив эшләре буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләргә гражданнардан һәм оешмалардан гариза кабул итү» темасына өйрәтү семинары үткәрелде. Семинар Яр Чаллы шәһәре, Гидротөзүчеләр урамы, 10 йорт адресы буенча урнашкан Күпфункцияле үзәктә үткәрелде, анда Үзәк КФҮнең 12 белгече катнашты.

Архив бүлегендә запросларны үтәгәндә иң күп күрсәтелә торган хезмәт булып архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив документлары күчермәләре бирү буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр санала. Гражданнардан һәм оешмалардан кергән запросларны үтәү белән бәйле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча административ регламентларда каралганча, запрос һәм административ процедураларны тайпылышсыз, билгеләнгән срокларда үтәүне тәэмин итү – бүгенге көндә архив алдында торган мөһим бурыч. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү срогы катгый рәвештә 20 көн дип регламентлана. Барлык запрослар да үз срогында үтәлде.

2018 елда архив бүлегенә запрослар белән **1290** – физик һәм **630** юридик зат мөрәҗәгать итте.

2018 елда **тематик запросларның** үтәлеше (шул исәптән милек запрослары – 198):

| Кергән запрослар саны | Үтәлгән запрослар саны | Уңай хәл ителгән запрослар саны |
|---|---|---|
| **422** | **422** | **399** |

2018 елда **социаль-хокукый характердагы запросларның** үтәлеше:

| Кергән запрослар саны | Үтәлгән запрослар саны | Уңай хәл ителгән запрослар саны |
|---|---|---|
| **1498** | **1498** | **1393** |

**Запросларның нинди ысул белән керүе**

| 2018 елда кергән запрослар | Шуның Россия почтасы аша кергәне | VipNet Client буенча Россия Пенсия фонды органнарыннан | КФУ аша АИС буенча | Шәхси кабул итү | Интернет аша кабул итү | Электрон документ әйләнеше аша | Архивның электрон адресы аша |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **1920** | **168** | **307** | **994** | **145** | **15** | **30** | **261** |